# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Стәрле Елга уамы (9 йорттан 26/2 йортка кадәр) гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

11 октябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Стәрле Елга урамы 9 йорттан 26/2 йортка кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу, шартнамә буенча эшләр башкару)" соравы буенча 2022 елның 11 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенныда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 44 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 32.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучының 32 кеше;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте**:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Стәрле Елга урамында (9нчы йорттан 26/2 нче йорт) гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. "Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән кала һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Стәрле Елга урамы 9 йорттан 26/2 йортка кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу, шартнамә буенча эшләр башкару)" соравы буенча үзара салым кертү буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 2 көн эчендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Э.Ә.Габдрахманов